УДК 070

**Илһам Фаил улы Фәттахов**
филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты

## ТЕЛЕВИДЕНИЕ ҺӘМ МАТУР ӘДӘБИЯТ

1959 елның ноябрь башында Казанның Шамил Госманов урамында телестудия ачылгач, әдәбият-сәнгать әһелләре әдәби-нәфис тапшыруларда актив катнаша башлыйлар. (2009 елның ноябрь аенда Татарстан башкаласында ТВ оешуның 50 еллыгы билгеләп үтелде.)

Бу хәл шул чор кешеләре көнкүрешендә телевизорның ныклап урын алуы, ТВнең совет җәмгыятендә роле елдан-ел артуы, Хрущёв "җепшеклеге"нең уңай нәтиҗәсе буларак СССРда демократия бераз үсү, коммунизм төзү өчен илнең барлык иҗат көчләрен туплау белән аңлатыла. Мәсәлән, 1960 еллар башында Казан университетында милли журналистикага нигез салучы танылган журналист, кыю публицист, кырыс тәнкыйтьче Гази Кашшафны, язучылар Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Ә.Еники, шагыйрьләр С.Хәким, Х.Туфан, әдәбият галимнәре Х.Госман, И.Нуруллин, Г.Халитны күпчелек телетамашачы ул чакта беренче мәртәбә зәңгәр экран аша күргән яки композиторлар Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарёв, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин музыкасының телеэфирда яңгыравын ишеткән.

60 елларның I яртысында "Татарстан" дәүләт телевидениесендә иҗат күтәрелеше аеруча сизелгән. Бу урында ТВдә татар әдәбиятын пропагандалауда титаник хезмәт башкарган ТР сәнгатенең атказанган эшлеклесе Әхтәм Зариповның режиссёрлык эшчәнлеген, әдәби-публицистик һәм документаль сценарийлар язуын аерым билгеләп үтәм. Ул Г.Камалның "Беренче театр", "Банкрот", К.Тинчуринның "Зәңгәр шәл", Ш.Камалның "Хаҗи әфәнде өйләнә" һ.б.ның пьесалары буенча беренче телевизион спектакльләр эшләгән. Ә.Зарипов 80 елларның II яртысында Г.Ахуновның "Идел кызы" әсәре, И.Газинең "Онытылмас еллар" трилогиясе, А.Гыйләҗевнең "Өч аршын җир" повесте нигезендә телефильмнар төшерде.

80 еллар ахыры – 90 елларда Татарстан ТВсе икенче мәртәбә иҗади күтәрелеш кичерде. М.С.Горбачёвның үзгәртеп кору сәясәте гражданнарга вөҗдан, сүз һәм матбугат иреге биргәч, язучы-депутатлар Р.Мөхәммәдиев, Т. һәм Р.Миңнуллиннар, Ф.Бәйрәмова, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Вәлиев ТВне сайлау алды кампаниясендә һәм сайлаудан соң

да татар халкының милли проблемаларын, әйтик, “тел”, “тарих”, “дәүләтчелек”, “бәйсезлек” төшенчәләрен аңлатканда рупор итеп оста файдаландылар.

ТВдә Роберт Миңнуллин (мәс., халык язучысы, Сталин премиясе лауреаты Г.Бәширов турында әдәби-документаль тапшыру), Әхтәм Зарипов белән Рәсим Мәһдиев (чишмәләр хакында тапшырулар циклы), журналистлар Риман Гыйлемханов (“Уйнагыз, гармуннар!”), Инсаф Абдулла (“Татар җыры”), Васил Гарифуллин һәм Илфат Фәйзрахманов (“Яңалыклар”) нәтиҗәле эшләп алдылар.

Риман Солтан улы Гыйлемханов – милли матбугатыбызда озак еллар эшләүче тәҗрибәле журналист, туры сүзле публицист, яшь каләмдәшләренең остазы. Ул ТВдә редактор булып эшләгән чакта кече һәм үсмер яшьтәге балалар өчен татар рухы, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияли торган телепрограммалар әзерләде. Сөекле халкыбыз арасында популярлашкан “*Уйнагыз, гармуннар!*” тапшыруын башлап җибәрде. Аның әлеге иҗат проекты *иң уңышлысы* булды. Күпсанлы тамашачылар мәхәббәтен яулаудан тыш, Татарстанның авыл һәм шәһәр урамнарында кыңгыраулы яшел гармун тавышы бик матур чыңлады, бу күркәм аһәң якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләргә дә барып ишетелде һәм бөтен җиһанга таралды. Татарлар 1990 елларда тальян гармун моңына уянды. “Уйнагыз, гармуннар!” телетапшыруы гомумхалык бәйрәме статусы алды һәм ел саен 30 августта зурлап уздырыла.

Җырчылар, ватанпәрвәрләр, дин әһелләре белән беррәттән күп кенә әдипләребез һөнәри журналистлар Эльмира Хамматова һәм Индус Сирматов оештырган “Җомга көн кич белән” әдәби-популяр тапшыруының даими кунаклары иде.

Тележурналистлардан беренче булып Хәйдәр Гайнетдинов Ислам дине, аерым алганда, Казан мәчетләре тарихына багышланган тапшырулар әзерләде. Аннары бу өлкәдә Рөстәм Гәрәев (“Дин һәм тормыш”, “Рухи хәзинә” программасы) байтак еллар эшләде.

Язучы Әхәт Мушинскийның “Яшел мич янында” (“У зелёного камина”) авторлык программасы татар әдипләре һәм галимнәре катнашында әдәбият, сәнгать, мәдәният мәсьәләләре хакында сөйләшү һәм фикер алышу рәвешендә барды.

1990 елларда Нәкый Исәнбәтнең “Мырау батыр” әкияте буенча кинорежиссёр Эдмас Үтәгәнов куйган телеспектакль яшь тамашачылар арасында зур уңыш казанды.

2000 еллар башында оештырылган “Яңа гасыр” (ТНВ) телеканалы татар милләтенең мәнфәгатьләрен кайгыртып, аның мәгълүмати ихтыяҗын канәгатьләндерергә омтылып эшли. “Татарлар” тапшыруын, “Мәдәният дөньясында”, “Кара-каршы” ток-шоуларын мисал итеп әйтергә мөмкин. Балалар һәм яшьләр өчен “Яшь ТНВ” проекты эфирда уңышлы эшли.

Әдәбият:
Баканов Р.П. «Книга жалоб» на телевидение: эволюция газетной телевизионной критики в Российской Федерации 1991-2000 гг. Монография. Казань: изд-во Казан. ун-та, 2007. 298с.
Даутова Р.В. Телевидение Татарстана: от прошлого к настоящему. Монография: изд. 2-е, доп. Казань: ЗАО “Новое знание”, 2010. 280 с.